# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 22 октябрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Түбән Якый авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 22 октябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлар, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Түбән Якый авылында механикалаштырылган кар чистарту хезмәтләре өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларга хезмәт күрсәтү;

- җәйге чорда Түбән Якый авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Түбән Якый авылында "Авыл бәйрәме" үткәрү , «Сабантуй», «Җиңү көне»" Өлкәннәр көне", "Инвалидлар көне", "Яңа ел" (бүләк, сувенир продуктлар сатып алу);

-күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу);

- трактор өчен асылма кораллар, ягулык-майлау материаллары , запчастьләр алу;

- трактористка хезмәт хакы түләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 175 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 93

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 93, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлар, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Түбән Якый авылында механикалаштырылган кар чистарту хезмәтләре өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларга хезмәт күрсәтү;

- җәйге чорда Түбән Якый авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Түбән Якый авылында "Авыл бәйрәме" үткәрү , «Сабантуй», «Җиңү көне»" Өлкәннәр көне", "Инвалидлар көне", "Яңа ел" (бүләк, сувенир продуктлар сатып алу);

-күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу);

- трактор өчен асылма кораллар, ягулык-майлау материаллары , запчастьләр алу;

- трактористка хезмәт хакы түләү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин